**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**С О В Е Т**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
тел./факс (8555) 41-70-00

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00


---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 18** **2015 елның 23 октябре**

**2013-2015 елларга Түбән Кама муниципаль милкен хосусыйлаштыру фараз планына (программасына) үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендә, 178 номерлы Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Советының 2011 елның 22 декабрендә кабул ителгән 40 нчы карары белән расланган «Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милкенә ия булу, алардан файдалану һәм эш итү тәртибе турында» гы нигезләмә нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2012 елның 26 ноябрендә кабул ителгән 55 номерлы карары белән расланган 2013-2015 елларга Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фараз планының (программасының) 2 бүлегендәге 2 пунктка, аны кушымта нигезендә редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Нижнекамская правда» газетасында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р.Метшин

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2015 елның 23 октябрендәге
18 номерлы карарына
кушымта

**Хосусыйлаштырырга планлаштырылган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге**

| № п/п | Исеме | Урнашу урыны | Гомуми мәйданы, кв. м, җир кишәрлегенең мәйданы, кв. м | Фаразланган хосусыйлаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Патологоанатомия корпусы | Түбән Кама шәһәре, Менделеевск урамы, 45 нче йорт | 268,3 | 2015 ел |
| 2 | Торак булмаган бина №1002 | Түбән Кама шәһәре, Вахитов проспекты, 9 нчы йорт | 140,2 | 2015 ел |
| 3 | Мәктәп бинасы | Түбән Кама районы, Камский бистәсе, Ленинград урамы, 1 нче йорт | 2196, Җир участогы 9955 кв.м | 2015 ел |
| 4 | Ачи мәктәбе бинасы | Түбән Кама районы, Ачи авылы, Мәктәп урамы, 26 нчы йорт | 280, җир участогы 483 кв.м | 2015 ел |
| 5 | Гаражлар | Түбән Кама шәһәре, Корабельная урамы, 38 нче йорт яны | 111,7 | 2015 ел |
| 6 | Гараж боксы | Түбән Кама шәһәре, мунча районында, Ахтүбә ГСК, 1нче йорт, 89 нчы бокс | 19,2 | 2015 ел |
| 7 | Төзелеп бетмәгән бина | Түбән Кама районы, Ильинка авылы (Сабантуй үткәрү урыны белән янәшә) | 1046,2 | 2015 ел |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8 | Җитештерү базасы | Түбән Кама шәһәре, Үзәк урамы, 85 нче йорт | 3937,8 | 2015 ел |
| 9 | АБК бинасы | Түбән Кама шәһәре, Менделеевск урамы, 46А | 334,7 | 2015 ел |
| 10 | Торак булмаган бина № 1001 | Түбән Кама шәһәре, Тынычлык проспекты, 10 нчы йорт | 71,9 | 2015 ел |
| 11 | Төзелеп бетмәгән төзелеш-стерилизация блогы | Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 6 нчы В йорты | 1293,9, җир участогы 1600 кв.м | 2015 ел |

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р.Долотказина